РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.03.2023 №250-п

Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда казначылык ярдәмен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 5 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда казначылык ярдәмен Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары тарафыннан казначылык ярдәмен гамәлгә ашыру тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 01 декабрендәге 2155 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

КАРАР БИРӘ:

1. 1. Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда акчаларны тотуда казначылык ярдәмен гамәлгә ашыру тәртибе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты карары нигезендә
_________________№________

## Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда казначылык ярдәмен гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясы нигезендә билгеләнгән муниципаль район бюджетыннан акчаларны тотуда казначылык ярдәме күрсәтелә торган катнашучыларга бирелә торган акчаларны тотуда казначылык ярдәме Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан (алга таба - максатчан акчалар, казначылык ярдәменең муниципаль катнашучысы) гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Максатчан акчаларны тотуда казначылык ярдәме белән тәэмин итү бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 5 пункты нигезендә товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турындагы муниципаль контрактлар (шартнамәләр) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Максатчан акчалар белән операцияләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының казначылык ярдәме күрсәтелә торган катнашучыларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасында билгеләнгән тәртиптә бюджет кодексының 220.1 статьясындагы 9 пункты (алга таба - шәхси счет) нигезендә һәм казначылыкта муниципаль катнашучылар тарафыннан шәхси счетны (шәхси счет режимын)алып бару һәм куллануда казначылык ярдәмендә бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән шартларын үтәп, билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Шәхси счетлар ачканда һәм күрсәтелгән шәхси счетларда операцияләр башкарганда бюджет мониторингы Бюджет кодексының 242.13-1 статьясы нигезендә башкарыла.

5. Максатчан акчалар белән операцияләр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан күрсәтелгән операцияләрне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләр) финанс органнары тарафыннан акчаларны тотуда казначылык ярдәмен гамәлгә ашыру тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 1 декабрендәге 2155 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә санкцияләүне гамәлгә ашырганнан соң шәхси счетларда үткәрелә.

6. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.24 статьясындагы 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән очракларда һәм тәртиптә киңәйтелгән казначылык хезмәте башкарыла.

7. Максатчан акчалар белән операцияләр башкарганда, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, максатчан акчалар күрсәтүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән муниципаль район бюджеты акчаларын алучы һәм акчаларны тотуда казначылык ярдәме күрсәтелә торган муниципаль катнашучылары арасында документлар алмашканда үзара хезмәттәшлек электрон рәвештә төзелә торган килешү нигезгдә, ә мөмкинлек булмаган очракта - кәгазь чыганакта гамәлгә ашырыла.